Бүгенге санда

МИКРОПЕРЕПИСЬ НАСЕЛЕНИЯ 2015

Районда микро сан алу бара. 2 бит.

Дуслык
Дружба

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Җомга **16** октябрь 2015 ел

№76 (10605)

17 октябрьгә һава торышы: болытлы һава, урыны белән яңгыр, җил көнбатыштан, 3-4 м/с; температура көндез +5°С, төнлә +4°С

КОТЛАУ

Хөрмәтле юл тармагы хезмәткәрләре һәм ветераннары!

Һөнәри бәйрәмегез – Юл хуҗалыгы хезмәткәрләре көне белән ихлас котлаулар кабул итеп алыгыз. Сезнең көндәлек хезмәтегез ярдәмендә безнең юлларыбыз һәм урамнарыбыз күпкә уңайлы, җайлы һәм куркынычсызракка әйләнә бара. Быел гына да юл эшләре программасы буенча торак пунктларга кадәр 9 километр юл салынды, 14 километрдан артыграк юл, ике күпер ремонтланды. Шәһәрнең 5 урамында юлларга муниципаль юл фонды хисабына ремонт ясалды, 6 авылда каты өслек түшәлде, 26123 кв. метр гамәлдәге асфальт катламы ремонтланды. Быел Төньяк-Көнчыгыш микрорайонында зур эш башкарылды, 34 йорт яны территориясе норматив хәлгә китерелде. Әлеге игелекле эшкә бу көннәрдә 40 еллык юбилеен билгеләп үтүче Нурлат автомобиль юллары идарәсенең керткән өлеше бик зур.

Хөрмәтле юл хезмәткәрләре, ветераннар! Киеренке һәм җаваплы хезмәтегез өчен рәхмәт сезгә. Нык сәламәтлек, иминлек һәм меңләгән чакрым яңа юллар салырга насыйп булсын!

Равил Кузюров,
Нурлат муниципаль районы
һәм шәһәре башлыгы

Юлга яңа тормыш бүләк итүчеләр

Автор фотосы

Илшат Гәрәев, Павел Алексеев һәм Андрей Андреев Кече Камышлыда чираттагы объектта

Кече Камышлы халкын быелдан юл өзеклеге куркытмас: шул көннәрдә Нурлат автомобиль юллары идарәсенең юл бригадасы 1600 метрга сузылган юлга асфальт-бетон катнашмасы түши башлады.

Әлеге җаваплы участокта участок начальнигы Павел Алексеев җитәкчелегендәге асфальт-бетон катнашмасы түшәү бригадасы мәшгуль.

– Авыл җирендә юллар салу аеруча күңелле, – ди участок начальнигы. – Әмма авыл кешеләре генә түгел, шәһәрләләр дә инфраструктураның яхшыруына ихлас шатланалар.

Биредә асфальт-бетон катнашмасын ике катлам итеп салачаклар. Әлеге эшләр чәршәмбе көнне башланган, атна азагына аны тулысынча төгәлләргә дә планлаштыралар. Монда 8 кеше, шулай ук 6 берәмлек техника: катоклар, су ташучы, түшәүче машиналар, грейдер эшли. Юлчылар эшләрен сыйфатлы һәм тиз башкаралар: октябрьдә һаваның аяз торуы – сирәк күренеш, шуңа күрә кояшлы көннәрдән файдаланып калырга ашыгалар. Хәер, Павел Алексеев әйтүенчә, бригада ышанычлы. Юкка гына ике хезмәткәргә НУАДның 40 еллыгына багышланган тантаналы чарада "Татнефтедор" ОООсының мактау грамоталары бирелмәде бит. Мисал өчен, грейдер белән вак таш җәюче Фәрхәт Гомәровның 35 еллык стажы бар, шуның 18 елы – НУАДта. Павел Алексеев та, предприятиедәге эш стажы әле 8 еллап кына булуга карамастан, үзен яхшы яктан гына күрсәтергә өлгергән. Ул башкарган эшләре өчен шатлык һәм горурлык хисләре кичерүен яшерми. Павел Алексеев әйтүенчә, юллар төзү һәм ремонтлау – иң күркәм һөнәрләрнең берсе. Шулай булмый ни, быел гына да НУАД юлчылары шәһәрдә 15 километрдан артык, шул исәптән йорт яны территорияләрен, авыл юлларын асфальтладылар. Ә бу йөзләгән нурлатлылар урамнарына һәм ишегалларына яңа тормыш бүләк иткән юлчыларны рәхмәт сүзләре белән искә алачаклар дигән сүз.

Сирень СӘМӘРХАНОВА

САННАР ҺӘМ ФАКТЛАР

Предприятиедә 124 кеше эшли, аларның уртача яше – 43.

2015 елның 9 аенда юлчылар 200 млн. сумлык эш күләме башкарган.

Предприятие карамагында рай ондагы 315 км. юл исәпләнә.

Автомобиль юллары идарәсенең автотрактор цехы 125 мең тонна материал ташыган.

Теманың дәвамы - Знче биттә.

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

ИНТЕРНЕТ – КУЛЛАНУЧЫЛАРНЫ ЯКЛАУЧЫ

Хәзер район кулланучылары үзләренең хокуклары турында тулырак мәгълүматны "Вконтакте" социаль төркеменнән таба алалар. Монда кулланучыларның хокукларын яклау мәсьәләләре буенча рәсми төркем булдырылган. Ә июнь аеннан башлап кулланучыларның хокукларын яклау мәсьәләләре буенча онлайн фикер алышу да ачылган.

АКТУАЛЬ

Комиссия хисап тотты

Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча район комиссиясенең чираттагы утырышы юл-урам челтәрен кышка әзерләү, җәяүлеләр катнашында һәлакәтләрне профилактикалауда яктылык кайтарткыч элементларны куллану кебек мәсьәләләрне үз эченә алган иде.

Агымдагы елның 9 аенда район юлларында теркәлгән 27 юл-транспорт һәлакәтендә 4 кеше үлгән, 33е төрле тән җәрәхәтләре алган, зыян күрүчеләрнең 5се – балалар. ЮХИДИ хезмәткәрләре әйтүенчә, атнаның чәршәмбе көне һәлакәтләргә аеруча "бай" санала икән. Юл һәлакәтләренең иң киң таралган төре – транспорт чарасының юл читенә төшүе булса, соңгы араларда җәяүлеләрне таптату очраклары да арткан. Яшь җәяүлеләр иминлеге район комиссиясе рәисе Әсхәт Габдуллинны да борчый. Бүгенге көндә Ключи поселогыннан шәһәрнең 3нче урта мәктәбенә йөрүче 28 баланың язмышы әлегә ачык кала бирә. Уку елы башланып 1,5 ай үтүгә карамастан, балалар мәктәпкә җәяү йөри бирә. Бу проблема да автобус маршрутын яңартуга килеп терәлгән. Район мәгариф бүлеге җитәкчесе Линар Маняпов әйтүенчә, әлеге балаларның әти-әниләре катнашында җыелыш узган.

– Әти- әниләргә балаларны башка мәктәпләргә күчерү һәм автобусларда бушлай йөртү буенча берничә вариант тәкъдим ителде, - ди Линар Нурисламович. – Тик әти-әниләр үзләре теләгән мәктәпне сайлый.

Җитәкче хәбәр итүенчә, хәзер "Нурлат АТП"сы җәмгыяте белән балаларны проезднойлар белән йөртү мәсьәләсе карала икән.

(Ахыры 2нче биттә)

АНОНС

СЕЗ БАЛАЛАР ТУКЛАНУЫННАН КАНӘГАТЬМЕ?

Районның мәгариф учреждениеләрендә балаларның тукланыу ничек оештырылган? Моңа ата-аналарның карашы ничек? "Дуслык" газетасы редакциясе бу уңайдан туры элемтәгә чакыра.

Фикерләрегезне 2–36–13 телефонына шалтыратып җиткерегез яки газетабызның nurlat-tat.ru сайтына языгыз.

РАЙОН ТОРМЫШЫ

Файдалы һәм конструктив очрашу

ҺӘР ОЧРАШУ КОНКРЕТ КАРАРЛАР КАБУЛ ИТҮ БЕЛӘН ТӘМАМЛАНА

Шәһәрнең үзәк микрорайонында яшәүче халыкны борчыган сораулар – инженерлык коммуникацияләрен, йорт яны территорияләрен төзекләндерү.

Совет урамы, 78-80 йортлары, Гыйматдинов һәм Мәктәп урамнарында яшәүчеләр шул сораулар белән район башлыгы Равил Кузюровка мөрәҗәгать иткән иделәр.

Очрашуда районның юл, торак-коммуналь хуҗалыклары хезмәтләре вәкилләре дә катнашты. Халыкның гозерләрен тыңлаган район башлыгы аралашуны алда телгә алган адресларда яшәүчеләр белән урында дәвам итте.

- Узган елдан старт алган йорт яны территорияләрен төзекләндерү эше шәһәрдә киләсе елда да дәвам итәчәк, - диде район башлыгы халык белән очрашу вакытында. – Һава торышы көйле торса, быел ук әлеге проблеманы хәл итү ягын карарбыз.

Район башлыгы кайбер проблемаларны урында ук хәл итте. Ә менә Гыйматдинов һәм Мәктәп урамнарында яшәүчеләрнең инженерлык коммуникацияләренә кагылышлы сорауларын Равил Әфраимович үз контроленә алды һәм средстволар эзләп, аны республика дәрәҗәсендә хәл итәргә кирәклеген аңлатты.

Район башлыгы белән очрашкан халык һәр мөрәҗәгать буенча тулы җавап алды.

Зилия ӘКСАНОВА

БЕР УЧ ХӘБӘР

ШӘҺӘР ҖИТӘКЧЕСЕ САЙЛАНДЫ

Кичә, 15 октябрь көнне, Нурлат шәһәре Советында чираттагы икенче сессия үтте. Депутатлар район башлыгы Равил Кузюров җитәкчелегендә башта шәһәр башкарма комитеты җитәкчесен билгеләү турындагы мәсьәләне карадылар. Шәһәр Советы депутаты Евгений Савинов үткәрелгән конкурсның барлык этаплары белән таныштырды, анда ике кандидат катнашкан. Ачык тавыш бирү нәтиҗәсендә, депутатлар тәкъдим ителгән рекомендацияләрне, кандидатларга таләпләрне исәпкә алып, шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе постына Нәгыйм Сафиуллинны сайладылар. Район башлыгы Нәгыйм Сафиуллинның Нурлатның үсеше хакына уңышлы эшчәнлек алып бару өчен бөтен сыйфатлары булуын билгеләп, җылы теләкләрен җиткерде. Биредә үк депутатлар даими комиссияләр составларын формалаштыру, җир һәм физик затларның милегенә салым мәсьәләләрен карадылар. Көн тәртибендәге барлык сораулар да Совет тарафыннан кабул ителгән карарлар белән нык ытылды.

Валентина ВАФИНА

Комиссия хисап тотты

(Ахыры. Башы 1нче биттә)

Моннан тыш, белем бирү учреждениеләрендә яктылык кайтарткыч киемнәр кию не оештыру буенча да комиссия әгъзалары уртага салып сөйләште. Сер түгел, мәктәп автобусларын кышка әзерләүдә проблемалар җитәрлек әле. Әсхәт Касыймович әйтүенчә, әлеге проблемаларны республика җитәкчелеге ярдәмендә хәл итәчәкләр.

Шәһәр җитәкчеләрен чөгендер һәм нефть ташучы машиналар борчый.

- Әлеге проблема күптәннән хәл итүне сорый, - ди шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Нәгыйм Сафиуллин. – Район кырларыннан чөгендер ташучы йөк машиналарының маршрутын үзгәртү, тентлар куллану, машиналарны кырдан чыкканда чистартуны оештыру кебек мәсьәләләр шәһәр юлларын сакларга ярдәм итәр иде.

Утырышта район юлларына хезмәт күрсәтүче оешмаларның кышка әзерлеге дә каралды. Әйтүләренчә, төбәкара юлларга хезмәт күрсәтүче Нурлат автомобиль юллары идарәсе кышкы сезонга 75 процент әзер. Предприятие җитәкчесе Фидаил Садыйков әзерлек эшләрен якын арада хәл итеп бетерергә ышандырды.

Утырышта алда телгә алынган барлык сораулар буенча да җаваплы затлар хисап тотты. Комиссия әгъзалары каралган мәсьәләләр буенча тиешле карарлар кабул иттеләр.

Зилия ӘКСАНОВА

Көтегез: сан алучы килә

МИКРОПЕРЕПИСЬ НАСЕЛЕНИЯ 2015

1 октябрьдән 31енә кадәр Россиядә үтүче микро сан алуга нурлатлылар да кушылды.

– Хәерле көн, мин – сан алучы, микро сан алу үткәрәбез.

Бу көннәрдә Мәктәп урамы һәм тыкрыгында яшәүчеләрнең ишекләренә сан алучы Нина Гыйләҗева шундый сүзләр белән шакый.

Нурлатлыларның күбесе Нина Александровнаны танып белә, озак еллар социаль яклау тармагында, аннан статистика бүлегендә хезмәт куйган бу ханым – һәрчак кешеләр арасында. Хәзер лаеклы ялда булса да, тик ята торганнардан түгел, Әлмәт дәүләт статистикасының Нурлат районындагы бүлегендә ике дә уйламыйча микро сан алуга аны җәлеп иткәннәр.

– Микро сан алуга әзерлекне әле узган елдан ук башлаган идек, - ди Нина Александровна. – Сан алуга Россиянең төрле төбәкләреннән аерым участоклар гына сайлап алынды. Нурлатта Мәктәп урамы һәм Мәктәп тыкрыгының бер өлеше керде. Узган елда ук бу участокны әйләнеп, исемлеккә кергән йортларны, фатирларны карап, мәгълүматларны реаль җирлектәгеләре белән чагыштырып чыктым. Статистика бүлегеннән бирелгән мәгълүматлар белән кайбер нәрсәләр туры килеп тә бетмәскә мөмкин бит. Мәсәлән, кайбер фатирлар торактан сәүдә объекты итеп үзгәртелгән. Быел исә шул участоктагы фатирлар буйлап йөреп, яшәүчеләрдән төрле темалар буенча 28 сорауга җаваплар алам.

Чираттагы фатир – Мәктәп урамының бер йортында. Хуҗабикә Гөлбану Айзатуллина сан алучыны ачык йөз белән каршы ала. Шәһәрдә микро сан алу үткәрелүеннән хәбәрдар булса да, Нина Александровна әлеге кампаниянең максатын һәм үткәрү тәртибе хакында аңлатуны кирәк дип таба.

– Сезнең мәгълүматлар конфиденциаль, алар санкцияләнмәгән файдаланудан якланган, - дип сүзен дәвам итә сан алучы һәм тәртип буенча сорауларны бирә башлый.

– Исемегез... Туган елыгыз... Нинди телләр беләсез?

Гөлбану Гаязовна һәр сорауга төгәл итеп җавап бирә, ә сан алучы аларны шунда ук планшет ярдәмендә электрон сорау алу битендә терки бара. Электрон юл белән эшләү – сан алуда яңалык әле. Әмма сан алучы әйтүенчә, программа бик җайлы эшләнгән һәм мәгълүматларны тиз арада һәм төгәл итеп теркәргә мөмкинлек бирә.

МИКРО САН АЛУ БАРЫШЫНДА

Алга таба сораулар социаль характердагылары белән дәвам итә.

– Сәламәтлегегезнең торышы ничек? Нинди керем чыганакларыгыз бар? Сезгә нинди дә булса ярдәм кирәкме?

Сан алучы әйтүенчә, халыкның, аеруча олы яшьтәгеләрнең күңеленә сорауларның соңгылары хуш килә. Бу хакта сорыйлар икән, димәк, юкка түгел, дип саный халык. Төрле елларда төрле сан алуларда катнашкан Гөлбану Гаязовна да бу яктан үз фикерен белдерергә ашыкты:

– Гадәттә бөтен ил буйлап үткәрелә торган сан алулар нәтиҗәләреннән чыгып, ниндидер үзгәрешләр, законнар кертелә. Сан алуда халыкның сәламәтлегенә, мәшгульлегенә, яшьрәкләргә демографик планнарына кагылышлы сораулар бирелә икән, димәк, алга таба бу юнәлешләрдә ниндидер үзгәрешләр кертү көтелә. Дәүләтнең бу яктан кайгыртучанлык күрсәтүе бик күңелле, әлбәттә.

Сан алучы белән сан алуда катнашучының очрашуы исә 15 минут дигәндә төгәлләнә дә. Нина Александровна планшетта "Эш төгәлләнде" дигән язу чыкканны көтә һәм хуҗабикә белән хушлашырга ашыга. Эш көне әле бетмәсә дә, аның соңгы көннәрдә үткәрелгән сан алуларның нәтиҗәләрен республика статистика үзәгенә юллыйсы бар. Аларны, гадәттә, сишәмбе һәм җомга көннәрендә җибәрәләр.

Участогымдагы 148 хуҗалыкның 100ләбендә булып чыктым инде. Бер көндә 10-15ләп гаиләдә сан алу үткәрергә өлгерәм. Гадәттә, иртәнге 10нан кичке 8нче яртыларга кадәр эшлим. Халыкның күбесе эштә бит, кайтканнарын көтәргә туры килә, - ди ул.

Сан алуда зур кыенлыклар белән очрашмаса да, халык арасында саклык чаралары күреп, сан алучыны фатирларына кертергә бик ашкынып тормаучылар да очрый. Әмма сан алучы моңа аңлап карый һәм Росстатта бирелгән таныклыгын, кирәге чыкканда паспортын күрсәтергә ашыга. Сан алучының тагын "Росстат" дип язылган зәңгәр төстәге портфеленнән һәм яктылык кайтарткычлы зәңгәр беләзегеннән дә танырга була әле.

Бу көннәрдә исә сан алу Чулпан авылының кайбер урамнарында да үткәрелә. Биредә сан алучы Венера Хәлимова эшне төгәллә тә килә инде. 1 октябрьдән ул 160лап хуҗалыкта сан алу үткәрергә өлгергән.

– Бары буш, кешеләр яшәми торган йортлар гына калып бара, – ди ул.

Шәһәрләләр сыман ук, авыл халкы да микро сан алуга аңлап карый һәм сан алучының сорауларына актив җавап бирә икән. Күрәсең, халыкның күбесе моның җитди кампания булуын аңлый. Микро сан алу 2020 елгы Бөтенроссия сан алуына әзерлекнең мөһим этабы, һәм аның нәтиҗәләре илнең халык составы турында актуаль мәгълүматлар алу белән бергә халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү чараларын эшләү, сәламәтлек саклау һәм белем бирү сыйфатын үстерүгә дә хезмәт итәргә тиеш бит.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

САН

Россиядә халык санын алу соңгы тапкыр 2010 елда үткәрелгән иде. Ул чагында сан алуда 141,18 млн. кеше катнашкан. Микро сан алуда Россиянең төрле төбәкләреннән 2,5 млн. кеше катнашачак.

НУРЛАТ АВТОМОБИЛЬ ЮЛЛАРЫ ИДАРӘСЕНӘ – 40 ЕЛ

"Киләчәккә без төзегән юл илтә"

Быел Нурлат автомобиль юллары идарәсенә 40 ел тула. Предприятие юлчылары җәен кызу кояш астында яңа юллар салалар, таушалган катламнарны яңарталар, кышын, әле тәрәзәләрдә утлар да кабынмаган иртәдә, алар транспорт һәм җәяүләләргә юллар "ачалар". 40 ел эчендә алар нурлатлыларга күпме юл бүләк иттеләр икән? Йөз, меңләгән чакрым... Бу чакрымнар артында, һичшиксез, предприятие коллективының фидакарь хезмәте ята.

Юбилей – яңа юл башы ул

Юлчыларның 40 еллык юбилейлары алдыннан тантаналы чара булып узды. Анда дәрәҗәле кунаклар да катнашты.

– Автомобиль юллары идарәсе коллективы алга куелган бурычларларны үтәп кенә калмыйча, перспективага да эшли, күрше районнарда юл хуҗалыгына кагылышлы мәсьәләләрне чишү буенча да зур эш алып бара, – диде бәйрәм тантанасында район башлыгы Равил Кузюров, НУАДның район тормышындагы ролен билгеләп. – Киләчәктә дә республика хөкүмәте, "Татнефть" куйган бурычларны лаеклы үтәп барырсыз, дип ышанам.

"Татнефть" ААҖнең транспорт идарәсе начальнигы урынбасары Фәрит Салихов юлчыларны "Татнефть" җитәкчелеге исеменнән сәламләде.

– Сез транспортчылар буларак та, юлчылар буларак та мактауга лаек, – диде ул нуадлыларны юбилей белән котлап.

Юбилей уңаеннан котлауларны юлчыларга ТР Дәүләт Советы депутаты, "Нурлатнефть" НГДУсы начальнигы Илгиз Салихов та юллады.

– Нәкъ менә безнең районда шундый юл идарәсе төзелү Нурлат өчен дә, "Нурлатнефть" өчен дә уңышлы булды, – диде ул. – Нефть объектларына, торак пунктларга илтә торган юллар сезнең көчегез белән ясалган.

"Татнефтедор" ОООсы директоры Рөстәм Гарифуллин коллективның вакытында һәм яхшы сыйфатлы юллар төзүен билгеләп үтте һәм предприятиегә озын гомер, уңышлар теләде.

Юлчыларны Нурлат автомобиль юллары идарәсе җитәкчесеФидаил Садыйков та котлады:

– Юлчыларның хезмәте – даими хәрәкәт ул, юлларның киләчәккә алып баруларына яшь чагымда да ышана идем, хәзер дә шулай. Бездә омтылыр урын да, үсеш өчен перспектива да бар, шөкер, "Татнефтедор" ОООсының сәясәте болар өчен мөмкинлекләр бирә. Югары тизлек һәм яңа технологияләр заманы безнең тармак алдына яңа бурычлар куя, ә үсеш программалары зур перспективалар ача. Без республиканың транспорт артерияләре хәрәкәт итү өчен максималь уңайлы, җайлы һәм куркынычсыз булсын өчен барын да эшлибез. Яңартылган юллар ярдәмендә кешеләрнең дә тормышы яхшы якка үзгәрә бит.

Юбилей чарасының тантаналы өлеше Нурлат муниципаль районы башлыгы, "Татнефтедор" ОООсы, Нурлат автомобиль юллары идарәсе исеменнән мактау грамоталары тапшыру белән тәмамланды. Ә бәйрәм үзе спорт бәйгеләре белән дәвам итте. Предприятиедә, сәламәт яшәү рәвеше үрнәге буларак, спорт ярышларында катнашу гадәте күптәннән яши. Аларның спорт архивында волейбол, теннис буенча призлы урыннар бар. Бу көнне дә "Нурлатнефть" НГДУсының Марат Хуҗин исемендәге спорт комплексында предприятиенең 4 командасы волейбол, теннис, аркан тартышуда үзара көч сынаштылар. Иң яхшы нәтиҗәне юл участогы подразделениесе командасы күрсәтте. Алкышлар астында аларга һәм II-III урынны алучы АУП һәм АТК командаларына истәлекле бүләкләр тапшырылды. Бәйрәм чарасы "Әти, әни һәм мин – спорт гаиләсе" ярышында гаилә командалары бәйгесе белән тәмамланды. Һәр команда яхшы спорт әзерлеген һәм җитезлеген күрсәтсә дә, бәйге булгач, иң лаеклысын сайларга туры килде. Һәм жюри әлеге исемгә Төхфәтуллиннар гаиләсе лаек дип тапты.

Предприятиенең юбилей көне тәмамланды. Әмма юлчылар идарәләренең үзләре төзегән юллар кебек үк озын гомерле буласына шикләнмиләр. Димәк, бәйрәмнең дә соңгысы түгел бу.

Безне бер максат берләштерә

НЕФТЬЧЕЛӘР АРТЫННАН

Нурлат автомобиль юллары идарәсенең тарихы 1975 елның октябренә барып тоташа, нефть чыгару Нурлатка якынлашкан вакыт була бу һәм ул Әлмәт УАДының автомобиль юллары участогы буларак оеша. Биш данә техника һәм ике вагончык – юлчылар предприятие биографиясен әнә шундый хуҗалык белән башлап җибәрәләр. Әмма инде икенче елны ук ДС-508 туглагычлы асфальт-бетон заводы беренче продукциясен бирә, инерт һәм башка материалларны кайтару өчен тимер юл тупигы төзелә. Ә асфальт-бетон катнашманың беренче тонналары Нефтьчеләр микрорайоны юлларына салына.

ЯҢА СТАТУСТА

1978 елның 7 сентябрендә юл предприятиесе елъязмасында яңа дата – бу көннән ул үз бурычларын Нурлат автомобиль юллары идарәсе булып яңа статуста үти башлый. Идарә үз җитештерүчәнлеген ике тапкырга арттыра.

– Якын-тирә районнарда нефтьчеләрнең эшчәнлеге активлашу белән эш диапазоны һәм күләме арта, каты өлекле автомобиль юллары төзелешен тизләтергә, подъездлар, мәйданчыкларны төзекләндерүне киңәйтергә кирәк була, - ди НУАД начальнигы Фидаил Садыйков. – Икенче туглагыч гамәлгә кертелә һәм идарә составына Чирмешән участогы алына.

НУАДның базасы киңәя һәм тулылана башлый: 30 автомашинага гараж, котельня, складлар, диспетчерлык бүлеге, административ-лаборатор корпус төзелә, тимер юл аша йөкләр кайтару өчен думпкарлар сатып алалар, ремонт базасын киңәйтәләр һәм җиһазландыралар һәм эре проектларны тормышка ашыра башлыйлар. Шуларның берсе – "Татнефть"нең җыелма отряды составында нефтьчеләр һәм төбәк өчен бик мөһим булган Нурлат-Әлмәт юлы төзелеше.

– Моңа кадәр Нурлат нефтьчеләре көзен һәм язын эш урыннарына вертолетлар белән, ә Нурлаттан Әлмәткә Чистай аша гына барырга мөмкин иде, - дип сөйли Фидаил Һадиевич.

Алга таба Нурлат юлчылары Аксубай һәм Чирмешән районнарында автоюллар челтәре сузалар. 1987 елда НУАД "Нурлатнефть" НГДУсының юл участогы итеп үзгәртелгәч тә, аларның эш һәм план күләмнәре кимеми.

– НУАДлылар элеккечә үк нефтьчеләрнең промысел юлларына һәм җитештерү мәйданчыкларына хезмәт күрсәтә, Чирмешән районын Самара өлкәсе белән тоташтыручы линия төзелешен алып баралар. Һәм перспективага йөз тоткан башка коллективлар сыман үк үсүләрен дәвам итәләр, – ди предприятие җитәкчесе.

АБЗ: ЯҢА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ҺӘМ СЫЙФАТ

– Узган елның мартыннан НУАД базасында өр-яңа асфальт-бетон заводы эшләп китә. Җиһазларны Кытай белгечләре җайлап җибәрә. Прораб Радик Ибраһимов әйтүенчә, АБЗда "кайнар чор" майдан октябрьгә кадәр, бу вакытта юл эшләре тулы куәтенә бара.

– Быелның 9 аенда завод 24 мең тонна асфальт-бетон катнашмасы ясады, - ди ул. – Җитештерүнең яңа технологиясе, иң беренче чиратта, салына торган юлларның сыйфатын яхшыртырга мөмкинлек бирде.

НУАДНЫҢ ТӨП БАЙЛЫГЫ – КЕШЕЛӘР

Предприятие үсешенә Һади Садыйков зур өлеш кертә, ул предприятие белән 15 ел – 1993 елдан 2008 елга кадәр җитәкчелек итә. Бу чорда эретеп ябыштыру һәм столярлык эшләре өчен бина, автомобильләр өчен җылы гараж төзелә. Моннан тыш, бүленеп чыккан һаваны дымлы чистартулы һәм һәркайсы сәгатенә 50 тонна җитештерүчәнлеккә ия ике яңа асфальт-бетон заводы, 2000 тоннага РВС битум саклагычы эксплуатациягә кертелә. Болар предприятиенең экологиясен яхшыртырга, җылылык энергиясен экономияләргә, материаллар бушату өчен мәйданнарны арттырырга мөмкинлек бирә. Базаның территориясен төзекләндерү буенча зур эш башкарыла.

Предприятиедә: "НУАДта очраклы кеше эшли алмый", - диләр. Моның белән килешми мөмкин түгел. Эш авыр, һәм мондый темпны тотарга һәркемнең хәленнән килми. Шуңа да монда сайлаган юлларына тугрылар кала. Мәсәлән, предприятиенең оешкан көненнән бирле биредә шоферлар Александр Маликов белән Александр Никифоров, автомобиль транспорты диспетчеры Ольга Тайбулатова эшлиләр. Машина йөртүче Николай Иванов предприятиедә 22 ел инде. Хезмәт һәм хезмәт хакы бүлеге инженеры Илнар Галәветдинов, автотранспорт чараларының техник торышы контролеры Вадим Нотфуллин, баш бухгалтер Мәүлия Хәмитованың да эш стажы 20 елдан артыграк.

– НУАДта төрле һөнәр ияләре хезмәт куя: газ һәм электр белән эретеп ябыштыручылар да, малярлар да, контролерлар да, - ди ул. – Әмма барыбызны да бер максат – автомобиль юлларын төзү һәм ремонтлау бурычы берләштерә.

ИГЕЛЕККӘ УРЫН ТҮРДӘН

Көндәлек мәшәкатьләр һәм җаваплы эш алып бару белән бергә предприятие җитәкчелеге иганәчелеккә дә зур игътибар бирә. 2015 елның 9 аенда НУАД район хастаханәсе, шәһәр мәктәпләренә, үз шефлыкларындагы Кычытканлы мәктәбе һәм шәһәрнең "Колосок" балалар бакчасына иганәчелек ярдәме күрсәткән. Аз керемле гаиләләргә ярдәм итү, сәламәтләндерү лагерьларына юлламалар, төрле игелек акцияләре – боларның барысы да юлчыларның актив катнашында бара. Моннан тыш, алар Сабантуй үткәргәндә дә даими ярдәм итә.

– Бу ел коллектив өчен үзенчәлекле. Предприятиенең юбилее Бөек Җиңүнең 70 еллыгына туры килде. Җиңү бәйрәменә без Иске Әмзәдәге һәйкәлне ремонтладык һәм авыл халкы тантаналы митингны яңартылган монумент янында үткәрде. Район хастаханәсендә Бөек Ватан сугышы ветераннары өчен палата җиһазларга булыштык, - дип сөйләде баш бухгалтер Мәүлия Хәмитова. Хәер, игелекле эшләре турында биредә бик сөйләргә яратмыйлар. Моны чын йөрәктән, файдасы тисен дип башкаруларын гына әйтәләр.

ҮРНӘК АЛЫР КЕШЕЛӘР БАР

Предприятие ветераннары НУАДта еш кунак була. Быелгы өлкәннәр декадасында да предприятие җитәкчелеге аларны кафеда җыйды, кунакларны район башкарма комитеты җитәкчесе Әсхәт Габдуллин сәламләде. Ул юл хуҗалыгы үсешенә керткән өлешләрен искә алып, аларга хезмәтләре өчен рәхмәт белдерде. Ә ветераннар үзләренең авыр хезмәтләре турында бик җиңел итеп сөйлиләр.

– Иң зур бәла начар юллар дип әйтәләр. Ә безнең предприятие бу бәладән котылырга ярдәм итә, - дип уртаклашты 2009 елда пенсиягә чыккан Галина Овчинникова. – Хәзер бит көзге юл өзеклегендә дә шәһәрдә түфлиләрдән йөрергә була. Димәк, юлчылар үз эшләрен яхшы башкара.

Ветераннар белән мондый очрашулар еш була. Казан, Биләр, Свияжск утрау-шәһәрчеге, Раифа монастыре – алар соңгы араларда барган истәлекле урыннарның кайберләре генә әле. "Ветераннар белән мондый аралашу бәләләп бетергесез", - диләр юлчылар.

Сирень СӘМӘРХАНОВА,
автор фотолары

Реклама хокукында

НУАД бәйрәменнән фоторепортажны nurlat-tat.ru сайтыннан карагыз

МАНЗАРА

ШӘҺӘР

Таучык та, таган да бар

Яңа таган-карусельләр кую вак әйбер кебек, әмма балалар күңелендә күпме шатлык һәм сөенеч тудыра бит алар!

Яңа кече архитектур корылмалар узган атнада Завод урамының 24нче һәм Ленин урамының 28нче йорт ишегалларында урнаштырылды. Саклагыч ленталарын алып та өлгермәделәр, бала-чага шунда ук таудан шуарга, таганда атынырга ашыкты.

"Экодом" ИК җитәкчесе Илфат Гәрәев әйтүенчә,ике балалар мәйданчыгын җиһазлау район башлыгы Равил Кузюровның, шулай ук шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Нәгыйм Сафиуллинның ярдәмнәре белән тормышка ашырылды. Бу микрорайонда шундый архитектур формалар өч йортта урнаштырылган. "Киләчәктә дә бу юнәлештә эшебезне дәвам итәчәкбез", – диде идарәче компания җитәкчесе район җитәкчелегенә халык рәхмәтен җиткереп.

Сирень СӘМӘРХАНОВА

ПАТРИОТИК ТӘРБИЯ

Призывниклар хәрби белгечлек үзләштерә

Чәршәмбе көнне ДОСААФ идарәсендә армиягә чакырыласы егетләр өчен "С" категорияле машина йөртү һөнәренә өйрәтү буенча курслар ачылды.

Армия сафларында хезмәт срогы кыскартылу хәрби әзерлеккә вакытны аз калдыра. Солдат учебкада нибары 3 ай өйрәнү уза, белгечлек алу өчен бу аз вакыт. Шуңа да хәрби комиссариатлар алдына призывникларны армия сафларына әзерләп җибәрү бурычы куела.

– Көзге чакырылышта гына да армия сафларына районнан 20 егет "С" категорияле хәрби машина йөртүче таныклыгы белән китәчәк, - ди шәһәр хәрби комиссары, полковник Заһир Абдуллин. – Авыр йөк машиналары – "Урал", "КамАЗ"лар барлык гаскәрләрдә генә түгел, тормышта да популяр.

Укулар башлану егетләр өчен икеләтә истә калачак. Бүген аларга теләкләрне районның беренче затлары җиткерде.

– Язгы чакырылышта армия сафларына китәчәк 50 егет авыр йөк машинасы шоферы һөнәрен үзләштерергә теләк белдерде, - ди районның ДОСААФ идарәсе рәисе Радик Гыйниятуллин. – Бездә алар хәрби комиссариат юлламасы аша 5 ай дәвамында белем алачаклар. ВУС-837 "хәрби машина йөртүче" белгечлеге бирү белән бергә хәрби яктан әзерлеккә дә зур игътибар бирәбез. Үзебездә үк спорт әзерлеген дә бирергә тырышабыз. Яшьләр өчен укулар дәүләт тарафыннан оештырыла.

- ДОСААФ һәм хәрби комиссариат тарафыннан яшьләргә һөнәр бирү – олы тормышка аяк басуда яхшы ярдәм, - ди район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җитәкчесе Әнәс Нәбиуллин. – Хәрби комиссариат линиясе буенча укулар узучы курсантлар машина йөртү күнекмәләрен хәрби машиналарда үзләштерәләр. Хәрби машина йөртүче һөнәре кат лаулы, шуңа да укулар кыса ларында курсантлар ГТО комплексларын да тапшыралар.

Зилия ӘКСАНОВА

ЕГЕТЛӘР АРМИЯГӘ ЯҢА ҺӨНӘР ҮЗЛӘШТЕРЕП КИТӘЧӘК

"СӨЙКЕМЛЕ ЕЛМАЮ" КОНКУРСЫНА

Көз белән саубуллашып

Сары яфраклы көзнең матурлыгы әлеге фотодагы кызның сак кына елмаюына, кәефенә аһәңдәш. Аның иясе – Эльвина Камалетдинова. Ул шәһәрнең 1нче мәктәбенең 4 сыйныфында белем ала. Сәйләннән үрү белән шөгыльләнә. Ә фоторәсем гаилә фотосессиясе вакытында төшерелгән һәм, күренгәнчә, үтеп баручы көзнең якты мизгелләрен чагылдырган.

Бергә күңеллерәк

Коллектив фоторәсемне конкурска Ирина Николаева алып килде. Егоркино авылы балалар бакчасының тәрбиячесе буларак, ул үз төркемендәге балаларны чыгарылыш кичәсендә фотога төшергән булган. Камера алдындагы оялчанлык һәм җитдилекне читкә куеп, балалар барысы да елмаеп төшкәннәр.

ТАБИГАТЬ МОГҖИЗАСЫ

Бусы – поши, бусы – үгез...

Кычытканлыдан Сабировларның йорт яны участокларында үскән гигант чөгендер халык әкиятендәге шалкан белән ярыша алыр иде.

Тамыразыклар үлчәмнәре белән генә түгел, формалары белән дә хәйран калырлык. Берсе үгез, икенчесе поши башын хәтерләтә, тик мөгезләре генә юк. Аларны тотып тору да җиңел түгел. Менә 4нче сыйныф укучысы Рузинә дә, "Дуслык"ка төшкәндә, соңгы көченә елмая. Бигрәкләр дә авыр шул могҗиза-чөгендер. Ун килограмм тирәсе яки аннан да артыграк булыр.

– Быел азык чөгендере дә, шикәр чөгендере дә уңды, – дип сөйли гаилә башлыгы Фалис Сабиров. – Чиләк кадәрләләрен дә аз җыймадык.

Ирле-хатынлы Фалис һәм Эльмира шәхси хуҗалыкларында 4 савым сыер, 5 үгез, 12 сарык тоталар. Чөгендерне дә терлекләргә ашату өчен 10 сутыйлы бакчада үстергәннәр. Шуның өстенә, печәнлек өчен 8 гектар җир арендалаганнар. Быел Сабировлар яхшы азык запасы туплаган. Әлеге эксклю зив экземплярлар да шунда китәчәк.

Маргарита ЛИТТ

КЫСКАЧА

Мәчетнең туу елы билгеле

Сентябрь ахырында Габдулла Кариев музеенда Биләр музей-тыюлыгы директоры Ә.Г.Кутуев һәм Татарстан мәдәният министрлыгы хезмәткәре Д.Абдуллина булды. Кунакларның Колбай Морасага килү максаты изге. Авылдагы мәчетнең "туу елын" тәгаенләп, фотосын төшерергә килгәннәр. Үз чиратыбызда, 2013нче ел башында Башкортостан дәүләт архивыннан без ул датаны белешкән идек. Тулы җавап алып, бик канәгать булып киттеләр. Әлеге мәгълүмат Татарстандагы архитектур һәйкәлләр җыентыгына керәчәк.

Гаилә ядкәре – музейда

Авылдашыбыз Мансур Гыйматдинов музейга әтисе - Гаваз Минһаҗ улының 1943нче елда Днепропетровскида төшкән фотосын тапшырды. Берничә көн элек дүрт туганы Г.Кариев музеена кереп, Сталинград өчен барган сугышларда әтисе катнашканын тагын бер кат искәртеп чыккан иде. Гаилә киңәшмәсен истәлеккә калган бердәнбер фотоны музе га тапшырырга булганнар. Ефрейтор Гав Гыйматдинов Берлинга кадәр барып житк Колбай Мораса зиратында жирләнгән.

Люзия ВӘЛИУЛЛИНА, Колбай Мораса авы

Яңа койма булачак

Иске Әлмәт авыл жирлеге үзара саль нан кергән акчага Яңа Әлмәт авылын тау башында урнашкан зират коймас тота башлаган. Эшкә Илшат Әхмәтов, Рә Борһанов һәм башка авыл кешеләре жәл ителгән. Авыл жирлеге зиратларны төзекл дерүгә зур игътибар бирә. 2013 елда ав уртасындагы зират коймасы иганәчеләр, ташлар, авыл халкы акчасына тотылган бу ган. Киләсе елда исә Иске Әлмәтнең зир тирәләрен буырга, православие зиратын зартырга планлаштыралар.

Гүзәл САДЫЙКО

НУРЛЫ ЯК

ГӨЛҮСӘ НУГАЕВА

Әниләр бар әле дөньяда

Үстек инде, күптән таралыштык...
Тормыш җиле каккан чагында,
Ярый әле, сагнып кайтыр өчен
Әниләр бар туган ояда.
Ашыктырып еллар куабыз ла,
Егылмаска текә кыяда,
Яктыртырлык итеп күңелләрне
Әниләр бар туган ояда.
Төрле яклап сынап карый язмыш –
Каршыбызга сорау куя да,
Ярый әле дога кылып торыр
Әниләр бар туган ояда.

ФӘҮЗИЯ МӨХӘММӘТОВА

Бер туташка...

Йөзең нурлы – тулган айдыр,
Йомры, җыйнак буй-сының.
Сөрмәле күз карашыңа
Бер карауда буйсынып,
Әсир итәр сәләтең бар,
Яраттырыр сәләтең.
Матурлык өләшкән чакта
Кызганмый мәрхәмәтен
Раббы сиңа мулдан биргән
Чын матурлыкның үзен.
Син дип, аһ иткәннәргә дә
Үзе үк бирсен түзем...

Гомер

Һәрбер туган алсу таңнар белән
Яшьлек ерагая, беләбез.
Ашыкмыйча, әкрен генә басып
Гомер көзләренә керәбез.

Төшләремә кергән һәр иртәдә
Алсу таңым – минем балачак.
Әниемнең моңлы бишек җыры
Гомерем буе озатып барачак.

Чиксез аяз зәңгәр күк йөзләре –
Яшьлегемнең зәңгәр кичләре,
Дәрьялардай ярсып-ташып тулган
Чикләнмәгән уйлар, хисләрем.

Ачык сары, кызыл, көрән төсләр –
Гомеремнең алтын көзләре.
Тормыш китабыннан акыл туплап
Җайлы гына яшәү көннәрем.

Ак кышка да инде ерак түгел,
Ап-ак төсләр – минем картлыгым,
Чигәләргә еллар көмеш сипкән,
Балаларым – дәвам-шатлыгым.

Яшел, коңгырт-кара һәм ак төсләр –
Узган тормышымның юллары.
Сизелмичә агып узып киткән
Мәңге онытылмаслык елларым.

Яшәү яме

Йөрәгемдә мәхәббәтем дөрли,
Күңелемдә сөю-назларым.
Ярларыннан тулып таша сыман
Ярсуларым минем – язларым.

ӘЛФИЯ ТӨХФӘТУЛЛИНА

Хыялларым ераклар оча,
Сүтеп ташлап богау-бәйләрен.
Алсу таңнарымда – тормыш яме,
Тынычлыгым минем – җәйләрем.

Уйланасы уйлар башта гына,
Үлчәнелгән әйтер сүзләрем.
Мул табыннар – яшәү чыганагы,
Сабырлыгым минем – көзләрем.

Яшәү ямен тоеп иркәләнәм,
Тирә-юньдә – якын дусларым.
Шөкер итеп яшим Ходаема,
Зирәклегем – ап-ак кышларым.

Синең юлың

Төшләремә бүген кердең әле,
Ераклар төбәп карашың,
Көмеш тәңкә сипкән киң юл буйлап
Кайларгадыр китеп барасың.

Төшләремә бүген кердең әле,
Һаман шулай матур икәнсең,
Ни өчендер пәлтә төймәләрен
Төймәләми генә кигәнсең.

Башың ялан, көмеш чәчләреңне
Җил тузгытып уза бер ара,
Иңнәреңә килеп сарыла да,
Кайларгадыр китеп югала.

Әкрен генә яуган ак карларны
Учларыңа җыеп аласың,
Нәфис тәңкә сипкән киң юл буйлап
Ераклар китеп барасың.

Юлың озын, күз күреме җитми,
Офыклар китеп югала,
Хушлашырга өлгермичә калам –
Мин сискәнеп ялгыз уянам.

***

Ераклар киткәнеңне беләм,
Ара ерак, юллар – бормалы.
Сагынуымны агымсуга салам,
Канатына – очкан торнаның.

Туган яктан килгән торналарны
Тавышыннан бәлки танырсың.
Каурыенда – сиңа дигән сәлам,
Сагына калсаң – табып алырсың.

Озын юлга җилләр сибә калса,
Гөлләр булып шытар сагыну.
Кошларда да миндә генә бугай
Бер сөюгә шулай табыну.

Кабат көзге күкне сискәндерә
Торналарның моңсу тавышы.
Әйтерсең лә, безнең гомерләрнең
Тезелешеп үтеп барышы.

***

Кайда син, мине яратып,
Аркамнан сөйгән җилкәй?
Назлы кояш, нурлы кояш,
Булдыммы синең иркәң?

СӘКИНӘ НУРУЛЛИНА

Ничәмә кат күмде яңгыр
Язгы җылы тамчыга,
Канатты да, яматты да
Кар-бозларның ярчыгы.

Сабыр бул, дип келәм җәйде
Җир сыенсам сагышта.
Йөгерек елга хәсрәтемне
Суларына салышты.

Тоймый калсам шул терәкне
Табигать-анабыздан,
Җылы кулын сузмый калса
Берәве арагыздан,

Яшәүнең бу рәхәтлеген
Татымас-тоймас идем.
Бәхеткә омтылырга да,
Билләһи, кыймас идем.

Уйлыйм да – уелып китәм:
Күпме игелек җирдә!
Рәхмәтемне ирештер, дип,
Тапшырдым җылы җилгә.

Якташыбыз истәлегенә

Самара өлкәсендә Гакыйль Сәгыйровның тормыш һәм иҗат юлына багышланган китап дөнья күргән.

"Гакыйль Сәгыйров. Үзе турында һәм аның турында барысы да" – сентябрь ахырында Самараның "Медиа-Книга" нәшриятында басылып чыккан китап әнә шулай атала. "Матбугат.ру" электрон сайтында Самара өлкәсенең "Бердәмлек" өлкә татар газетасы баш мөхәррире Рәфгать Әһлиуллин хәбәр итүенчә, китап төрле елларда төшерелгән аклы-каралы һәм төсле рәсемнәр белән бизәлеп, 700 данәдә, 320 битле булып басылып чыккан һәм Самара өлкәсе хөкүмәтенең өлкә татар милли-мәдәни автономиясенә биргән губерна гранты акчасына нәшер ителгән. Шагыйрьнең үзе, әти-әнисе, туганнары, бергә укыган сыйныфташлары, авылдашлары, фикердәшләре, ярдәмчеләре турында язылган документаль хикәяләре, публицистик язмалары һәм аның турында күп истәлекләр урын алган әлеге китапка язмаларны да Рәфгать Әһлиуллин туплаган һәм әзерләгән. Аны дөньяга чыгаруда исә редакция коллективы хезмәт куйган. Шагыйрь турында китап дөнья күрү, һичшиксез, гаҗәеп зур ихтыяр көченә ия талантлы һәм бөек шәхес, якташыбыз Гакыйль Сәгыйровның исемен мәңгеләштерү һәм аның турында яшь буыннарга җиткерүгә хезмәт итәчәк.

Самара өлкәсендә октябрь азагында китапны тәкъдир итү кичәсе дә оештырырга ниятлиләр. Ә китапны Гакыйль аганың гомер юлы узган Самара, Димитровград һәм безнең Нурлат районы татар авыллары китапханәләренә һәм мәчетләренә таратырга планлаштыралар икән.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

РОЗА МӘСЛАХОВА

Йокымсырап көзләр иңгән мәлдә
Сискәндереп күкләр күкрәде,
Яңгыры да чиләк-чиләк койды,
Салкын җилләр давыл китерде.
Ерагайган кояш болыт аша
Сирәк-мирәк кенә күренә,
Әче җилдән гаҗиз булган мизгел,
Салкын үтә бәгырь түренә.
Кара болыт күкне капласа да,
Бозлы яңгыр җанны өшетсә,
Әбиләр чуагын күңел кәтә,
Кояшлы көн әле өметтә...

***

Сине сөю белән
Янып яшәвем,
Ишет әле, бәгырем,
Сиңа дәшәмен.
Сиңа җыйган чәчәк –
Гөләп кулымда,
Гөләп чәчәгем бул
Гомер юлымда.
Гөләп чәчәгем дип
Кадерләп, сөеп,
Һәрчак эндәшермен
Җаныем, диеп.
Алларыңа, бәгырем,
Гөлләр сибәрмен,
Өзмә өметемне,
Гөләп чибәрем.
Тидермәм салкын җил
Саклап кочакта,
Бәхетле булырбыз
Җылы учакта,
Бергә шул чакта.

ИЛҺАМИЯ

Хәтерләрдә исәп батырлар

300 батыр, азмы, күпме дисең,
Кемнәргә күп, кемгә азрак.
Кайтмый калган сөйгән ярын эзли
Кыр капкасы буйлап ялгызак.

Сабан туе көнне авылымның
Алсуланып таңы атканда,
Ир-егетләр китте ил сакларга
Күз күрмәгән ерак якларга.

Ак яулыгы читен тешләп озатты,
300 баһадирын авылым.
Каһәрләде аксакаллар ярсып,
Гитлер ачкан сугыш давылын.

Тальян гармун, "Герман көен" тартып,
Яулык изәп китте егетләр,
Кара кәгазь өзде үзәкләрне,
Өзелмәде көткән өметләр.

Җиңү килде, озын юллар аша,
Ерак калды даулы ул көннәр.
Хәтерләрдә исән, һаман бала,
Көт, кайтырбыз, диеп киткәннәр.

ИЛСУР ЗӘЙДУЛЛА

Кышкы урман

Кышкы урман, көттеңме син мине,
Каршы алырсыңмы бер килсәм?
Ничек тә бер вакыт табар идем,
Көткәнеңне әгәр мин белсәм.
Сагындыра яшел чыршыларың,
Карлар баскан ялан ботаклар.
Бер кыз булсаң, ике уйламыйча
Үбәр идем сине, кочаклап.
Сиңа кайтсам, тынгы табам бит мин,
Сиңа кайтсам, йөрәк яшәрә.
Насыйп итсен, тоеп тынлыгыңны,
Сихрилегең күреп яшәргә!

Кышкы салкыннар

Җилләр тынган, озак бураннан соң
Ял итәләр агач, чыршылар.
Төнге күктә йолдызлары балкый,
Ай чайкала таңны каршылап.
Башны иеп җил-буранга каршы
Барасы юк бүген, эш беткән.
Әнә берәү кинәт салкынлыктан
Тулып торган битен өшеткән.
Күренмиләр кар да көрәүчеләр,
